РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
РУНГИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН ЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЫРЫҢГЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03.06.2024г. № 1-93

«Җир салымы турында»
2019 елның 23 октябрендәге 1-73 номерлы
ТР Буа муниципаль районының Ырынгы авыл
җирлеге Советының карарына үзгәрешләр
кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлегенә ярашлы рәвештә, Ырынгы авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. «Җир салымы турында» 2019 елның 23 октябрендәге 1-73 номерлы Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Ырынгы авыл җирлеге Советы карарына (03.03.2020 № 1-79, 16.11.2020 № 2-5, 30.12.2022 №2-61 номерлы карарлар редак.) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1. 2 статьяда:

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары белән биләнгән җир кишәрлекләренә (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез милек объектына туры килә торган җир кишәрлегенең бер өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата 0,1% шәхси торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән), эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган җир кишәрлекләре;»;

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралганча, шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык яки бакчачылык алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә кулланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата 0,1% »;».

3, 4, 5, 6 нчы пунктларда «кадастр бәясеннән» дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

1.2. 4 статьяның 2 пункты үз көчен югалткан дип танырга.

1.3. 5 статьяны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә язарга:

«Салымны салым түләүче оешмалар салым чоры тәмамланганнан соң 28 февральдән дә соңга калмыйча түләргә тиеш. Салым буенча аванс түләүләр салым

түләүче-оешмалар тарафыннан хисап чоры тәмамланганнан соң айның 28 нче көненнән дә соңга калмыйча түләнергә тиеш.

Салымны салым түләүче физик затлар салым чоры тәмамланганнан соң киләсе елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча түләргә тиеш.».

1.4. 7 статья үз көчен югалткан дип танырга.

1.5.8 статьяны түбәндәге эчтәлектәге 3 пункт белән тулыландырырга:

«3. 1.3 пунктчасы нигезләмәләренең гамәлдә булуы. әлеге карарның 4 статьясының 1 пункты 2023-2024 елгы салым чорларында җир салымын исәпләү белән бәйле хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә (http//buinsk.tatarstan.ru) рәсми рәвештә басылып чыккан көннән законлы көченә керә .

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет Рәисе,
Буа муниципаль районы
Ырынгы авыл җирлеге башлыгы Р.И.Гордеев